Том 1, выпуск 5 Март / 2025

МБМБУ «Яңа Кенәр балалар бакчасы»

# Чишмә башы

*Ананың балага биргән иң зур бүләге-тел.*



## Март аенда

Кар дип җиргә басасың,
Суга кереп батасың.
Чыксын инде умырзая
Кар астында ятмасын.

Мартлар җитсә, яз җитә,
Бураннары булса да,
Песи чыккан урамга
Аяклары туңса да.

(Ә.Бикчәнтәева)



Март аенда, кар өстендә
Кояш нурлар уйната –
Яз килә, каршы алыгыз –
Дигән хәбәр тарата.



Без беләбез, җылы язның
Иң беренче бәйрәме –
Әниләр, әби-апалар,
Хатын-кызлар бәйрәме!








# *Сыерчыклар кайтты!*

**ҖАВАПСЫЗ ТАБЫШМАК**

Очып баручы сыерчык көтүе үзенең оешканлыгы белән күпләрне гаҗәпләндерә. Көтү эчендәге меңләгән сыерчык барысы берьюлы хәрәкәтләнә, мәтәлчек атынып очыш хәрәкәтләрен үзгәртә. Әлеге кошларның мондый бердәм хәрәкәтне тудыра алу мөмкинлекләрен бер галимнең дә аңлата алганы юк.

## Сыерчык



Шатлыгы сыймый эченә,
Сайрый ул сузып-сузып.
Йә әйләнә бытбылдыкка,
Йә җырлый тургай булып.

Бака булып та бакылдый,
Тартар да була ала.
Кызылтүш кебек тә сайрый,
Канатын кага-кага.

Юкка сөенми, аңа бит
Бик ошый яңа оя.
Шуны ясап биргән өчен,
Ул безгә концерт куя.

*Нәҗип Мадьяров*

# *Кадерен беләбезме?*

## 22 март – Бөтендөнья су ресурслары көне.

Планета халкын су белән тәэмин итү глобаль проблемага әйләнеп бара. Бүген Җир шарында яшәүче халыкның 60 процент чамасы чиста суга мохтаҗлык кичерә. Бөтендөнья Азык-төлек оешмасы фаразлары буенча, 2025 елга планетада яшәүче халыкның 1,8 миллиарды даими рәвештә суга кытлык булган илләрдә яшәячәк. Шул ук чыганакларга караганда, соңгы йөзьеллыкта су куллану темпы-ның дөньяда халык саны үсү күрсәткеченнән ике тапкырга якын арткан күзәтелгән.
Бөтендөнья су ресурслары көнен дөньякүләм әһәмияттәге дата буларак билгеләүнең сәбәбе дә шушы проблемалар белән бәйле. Җәмәгатьчелек-нең, халыкның һәм власть органнарының игътибарын су чыганакларына, объектларына җәлеп итү, кешеләрдә таби-гатькә карата сакчыл караш тәрбияләү максатыннан 1992 елның 22 мартыннан Бөтендөнья су ресурслары көне билгеләнә. Ул Рио-де-Жанейрода Берләшкән Милләтләр Оешмасы үткәргән тирә-як мохитне саклау буенча конференция карары нигезендә ЮНЕСКО Халыкара су белән тәэмин итү ассоциациясе тәкъдиме белән уздырыла.

Бакчабызда  бу көн уңаеннан төрле чаралар узды.







Болар кызыклы!

* Суның 1500гә якын төрдәге формасы бар – кар суы, туфрак суы, яңгыр суы һ.б.
* Кеше су эчмичә 5 көннән дә артык яши алмый.
* Теоретик яктан караганда, әгәр планетадагы барлык бозлыклар да эресә, су дәрәҗәсе әлегедән 60 метр биеклеккә күтәрелер, коры җир өстенең 15 проценты су астында калыр иде.
* Кеше елына уртача 60 тонна су куллана.
* Кайнар су салкынына караганда тизрәк туңа.
* Тикшеренүләр күрсәтүенчә, су инфракызыл радиацияне үзенә яхшы йота.
* Әлеге вакытта планетада яшәүче бер миллиардка якын кеше саф су эчүдән мәхрүм. Соңгы 50 ел дәвамында су ресурсларына ия булу максаты белән дөньяда 20дән артык зур хәрби бәрелеш булган.
* Барлык йогышлы авыруларның 80 проценты чамасы кешегә су аша күчә. Фәкать шушы сәбәп белән дөньяда ел саен 25 миллион кеше үлә. Бу — Австрия дәүләте халкы кадәр!
* Иң нечкә су агынтысы да көненә бер мең литрга якын суның әрәм булуына сәбәпче.
* Галимнәр суның мәгълүматларны үзләренең “хәтерендә” сакларга сәләтле булуын дәлилләгән.
* Яңа туган сабый организмы 80 процент судан торса, картайган кешедә ул 50 проценттан артмый.
* Җир мантиясендә, аның өслегендәге белән чагыштырганда, су запасы дистәләрчә тапкыр күбрәк.
* Ел саен уртача бер триллион тонна су парга әйләнә. Ул унике нольле сан белән билгеләнә.
* Планетадагы суның 46 проценты Тын океанда тупланган. Атлантик океанда аның — 23, Һинд океанында — 20, Төньяк боз океанында 4 проценты.
* ЮНЕСКО бәяләмәсе буенча, дөньядагы иң саф су Финляндиядә.
* Галимнәр исәпләп чыгаруынча, дөнья океанындагы ресурслар 300 миллиард кешенең тамагын туйдырырга җитәрлек.
* Кениядә су бәясе АКШтагыдан 10 тапкыр кыйммәтрәк.

· Телефон: 8(84366)91-1-32
422031, Республика Татарстан, Арский район, с.Новый Кинер, улица Пионерская, дом 10

*Муниципальное бюджетное дошкольное образовательное учреждение «Новокинерский детский сад» Арского муниципального района Республики Татарстан функционирует с 30 декабря 2003 года.*

**График работы МБДОУ «Новокинерский детский сад":**

Понедельник - с 7.00 до 17.30

Вторник – с 7.00 до 17.30

Среда - с 7.00 до17.30

Четверг - с 7.00 до 17.30

Пятница - с 7.00 до17.30

[ адрес официального сайта ДОУ: https://edu.tatar.ru/arsk/n-kiner/dou ]